Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче Димтамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«03» декабрь 2025 ел № 23

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенә керүче Димтамак торак пунктында 2025 елның 03 декабрендә узган гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«2025 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы 12 санлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип танырга һәм "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Димтамак-торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Димтамак торак пунктында урамнарны яктырту фонарьлары сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Димтамак торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Димтамак торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (реконструкция, асфальт салу, ремонтлау, вак таш салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 399 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 202 граждан, бу 50,6% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 202 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. ««2025 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Димтамак торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы 12 санлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип танырга һәм "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Димтамак-торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Димтамак торак пунктында урамнарны яктырту фонарьлары сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Димтамак торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Димтамак торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (реконструкция, асфальт салу, ремонтлау, вак таш салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) – сорауларын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә(http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов